ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.07.2015 № 195

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау турында**

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ санлы Федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 санлы карары нигезендә,

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен әлеге боерык кушымтасы нигезендә расларга.
2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының структур подразделениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты
боерыгына кушымта
14.08.2015 ел № 195

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының (алга таба - Дәүләт комитеты) норматив хокукый актларына (алга таба - актлар) һәм норматив хокукый актлары проектларына (алга таба - актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибе (алга таба - Тәртип) Дәүләт комитеты актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүне кертеп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Дәүләт комитетының эшләнеп килгән актлар проектларына хокукый экспертиза һәм Дәүләт комитетының кабул ителгән карарлары мониторингысын үткәрү барышында коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны алга таба юкка чыгару максатында уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль төстәге мәгълүматны тәшкил иткән актларга, акт проектларына карата үткәрелми.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза гамәлдән чыккан яисә үз көчен югалткан актларга карата үткәрелми.

1.5. Дәүләт комитетында актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза оештыруның төп принциплары булып түбәндәгеләр тора:

1) акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең мәҗбурилелеге;

2) актларны башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә бәяләү;

3) актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезлелеге, объектив карашка һәм тикшерү мөмкинлегенә ия булу;

4) актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүче затларның компетентлылыгы;

5) актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү барышында Дәүләт комитетының, шулай ук аның вазыйфаи затларының гражданнар җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеге.

## 2.Дәүләт комитеты актларына һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 санлы карары белән расланган норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Методикасы нигезендә үткәрелә.

2.2. Актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза юридик бүлекнең вәкаләтле заты тарафыннан үткәрелә.

2.3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә килгән актлар норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза Кенәгәсенә (алга таба - Кенәгә) (1 нче Кушымта) килгән көнендә үк теркәләләр.

Коррупциоген факторларны куллану мониторингысын үткәрү барышында вәкаләтле зат тарафыннан Дәүләт комитеты актларында коррупциоген факторлар ачыкланганда, актлар коррупциоген факторлар ачыкланган көнне үк Кенәгәгә теркәләләр.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт проекты теркәлгән көннән алып биш көн эчендә үткәрелә.

2.5. Актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре юридик бүлек башлыгы кул куйган юридик бүлек вәкаләтле затының бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә.

2.6. Коррупциоген факторлар ачыкланганда, бәяләмәдә (2 нче Кушымта) Методика нигезендә ачыкланган барлык коррупциоген факторлар яктыртыла.

Бәяләмә үз эченә актта ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару ысулы турында тәкъдимнәрне алырга тиеш.

Бәяләмә бер эш көне эчендә, юридик бүлек башлыгы кул куйган мизгелдән, Дәүләт комитеты рәисенә юнәлтелә.

2.7. Дәүләт комитеты рәисе актта коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә нәтиҗәләре буенча аңа үзгәрешләр кертү яисә аны үз көчен югалткан дип табу турында карар кабул итә.

2.8. Актны әзерләгән структур подразделение өч көн вакыт эчендә коррупциоген факторларны юкка чыгару максатында үзгәрешләр кертү турында Дәүләт комитеты акты проектын яисә үз көчен югалткан дип табу турында акт проектын әзерли һәм аны юридик бүлеккә коррупциягә каршы экспертизага юнәлтә.

2.9. Коррупциягә каршы экспертизага юнәлтелгән акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланганда, вәкаләтле зат 2 нче Кушымтада бирелгән формада бәяләмә төзи, коррупциоген факторлар ачыкланмаганда,
3 нче кушымтада бирелгән формада бәяләмә төзи.

Бәяләмәгә юридик бүлек башлыгы кул куя һәм ул акт проектын юнәлткән структур подразделениесенә җибәрелә.

2.10. Коррупциоген факторлар ачыкланганда, акт проектын эшләүче структур подразделение, өч көн эчендә акт проектын эшләп бетерергә һәм аны

юридик бүлеккә коррупциягә каршы кабат экспертиза үткәрү өчен юнәлтергә бурычлы. Коррупциягә каршы кабат экспертиза өч көн эчендә үткәрелә.

2.11. Эшләнеп беткән акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланмаганда, вәкаләтле зат актны коррупциягә каршы экспертизага юнәлткән структур подразделениесенә бәяләмә җибәрә.

2.12. Структур подразделение (акт эшләүче) эшләнеп беткән акт проектын кызыксынган структур подразделениеләр җитәкчеләренең рөхсәт имзалары белән Дәүләт комитеты рәисенә имза куюга юнәлтә.

2.13. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Кенәгәдә яктыртыла.

## 3. Дәүләт комитетының актларына һәм акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәренең Дәүләт Советының рәсми сайтында - http://kt.tatarstan.ru (алга таба – сайт) урнаштырылган Дәүләт комитетының рәсми рәвештә басылган актлары һәм акт проектлары тора.

3.2. Дәүләт комитетының акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Дәүләт комитетының җаваплы структур подразделениесе, юридик бүлеккә карау өчен юнәлтелгән көнгә туры килгән эш көнендә эксперт бәяләмәсен юнәлтү өчен адресны күрсәтеп (шул исәптән электрон почта адресын да), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм кабул итүне туктату көннәрен күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.

3.3. Сайтта урнаштырырлган акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза кимендә биш көн эчендә үткәрелә.

3.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитетына килгән бәяләмә (алга таба - бәяләмә) актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы булган структур подразделениесенә карап тикшерү максатында юнәлтелә.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим рәвешендә кертелә һәм ул Дәүләт комитеты тарафыннан мәҗбури каралырга тиеш. Бәяләмә алынган көннән алып 15 көн эчендә Дәүләт комитетының структур подразделениесе бәяләмәне карап тикшерә һәм бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару ысулы турында тәкъдимнәр булмау очрагыннан тыш, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яисә физик затка дәлилләнгән җавап юнәлтә.

3.6. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү барышында коррупциоген факторлар ачыкланганда, алар актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты структур подразделениесе тарафыннан Тәртипнең 3.5. пунктында билгеләнгән вакытка юкка чыгарыла.

3.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән күрсәтмәләрне юкка чыгарганнан соң һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, актны әзерләү өчен җаваплы булган Дәүләт комитетының структур подразделениесе акт проектын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, юридик бүлеккә кабат карап тикшерү өчен юнәлтә. Кабат карап тикшерү өч көн вакыт эчендә эшләнергә тиеш.

3.8. Әгәр актта коррупциоген факторлар ачыкланса, актны әзерләгән Дәүләт комитетының структур подразделениесе бәяләмә Дәүләт комитетында теркәлгән көннән өч көн вакыт эчендә актка үзгәрешләр кертү яисә аны үз көчен югалткан дип табу буенча чаралар кабул итә.

3.9. Әгәр Дәүләт комитеты үзе тарафыннан эшләнгән Дәүләт комитеты актларында һәм акт проектларында коррупциоген факторлар ачыклануны таныклаучы коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәсә, ул күрсәтелгән актларны (акт проектларын) Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре бәяләмәсен һәм килешмәгәнлеген дәлилләгән аңлатма язуын теркәп, коррупциягә каршы экспертизага юнәлтә.

\

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә 1 нче кушымта

## Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза Кенәгәсе

| № | Коррупциягә каршы экспертизага юнәлтелгән акт һәм акт проекты турында мәгълүматлар | Коррупциягә каршы экспертизага керү көне | Актны (акт проектын) эшләүче структур подразделениесе атамасы | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре: бәяләмә, җаваплы зат имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә 2 нче кушымта

Коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә

___

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 санлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Методикасы нигезендә коррупциоген факторларны ачыклау һәм соңыннан аларны юкка чыгару максатында

___

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тәкъдим ителгән___

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

коррупциоген факторлар ачыкланды ___

(коррупциоген факторлар төре күрсәтелә)

___

Ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару максатында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

___

(коррупциоген факторларны юкка чыгару ысулы күрсәтелә)

___ ___ ___

(вазифа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия) ( дата)

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә 3 нче кушымта

Коррупциоген факторлар булмау турында бәяләмә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 санлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Методикасы нигезендә коррупциоген факторлар ачыклау һәм соңыннан аларны юкка чыгару максатында

______________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Актның( акт проектының) керү датасы:

Экспертиза үткәрү көне:

Тәкъдим ителгән акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланмады.

_____________________________ __________ __________________________

(вазифа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия) ( дата)